СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 182 от 21.02.2023
На № __________ от ____________

# КАРАР

2023 елда Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районында муниципаль
хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс җирле үзидарә органнарында һәм Саба муниципаль районы муниципаль органнарында үткәрелмәскә мөмкин дип билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов